# 2021 елда пенсияләрне 6,3 процентка индексацияләячәкләр.

***2021 елның 1 гыйнварыннан барлык иминият пенсияләре дә 6,3 процентка индексацияләнәчәк, дип яза «Парламентская газета» .***

Федерация Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары Елена Бибикова сүзләренчә, гамәлдәге законнар нигезендә эшләмәүче пенсионерларның барлык иминият пенсияләренә, картлык буенча пенсияләрне дә кертеп, 1 гыйнвардан индексация үткәрелә. РФ Президенты Владимир Путин сентябрь аенда сенаторлар белән узган очрашуда, илдәге социаль-икътисади вазгыятькә дә карамастан, иминият пенсияләренең индексацияләнәчәге хакында белдергән иде. Пенсия уртача алганда мең сумга артачак.

Сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлар ала торган акчалата түләүләр 1 февральдән артачак. «Биредә индексациянең күләме моннан алдагы ел өчен куллану бәяләре индексыннан чыгып билгеләнә, әлегә ул 3,8 процент тәшкил итә», — диде Бибикова.

Социаль пенсияләр 1 апрельдән индексацияләнәчәк. Әлеге пенсия шулай ук «пенсионерның яшәү минимумы фаразланган үсеш индексы» күләменә карап ел саен күтәрелә. Әлегә ул 2,6 процент тәшкил итә, әмма бу күрсәткеч үзгәрергә дә мөмкин.




24.11.2020 ел